КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 сентябрь г.Казань № 1043

Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына Тәртипкә таянып эш итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына аңа таянып эш итүне тәкъдим итәргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 28 сентябрь, 1043 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына
максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору
тәртибе

1. Бу Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору тәртибе түбәндәге максатларда эшләнгән:

Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычы дәрәҗәсе билгеләнү турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм аларның критик мәгълүмат инфраструктурасы субъектлары булган ведомство буйсынуындагы оешмаларына кичектергесез хәбәр итү;

Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору буенча чараларны тормышка ашыру һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту;

Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуны кисәтү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү.

2. Бу Тәртип Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм аларның критик мәгълүмат инфраструктурасы субъектлары булган ведомство буйсынуындагы оешмаларының мәгълүмат инфраструктурасына карата гамәлдә була.

3. Максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычы дәрәҗәсе мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычы янаганда дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм аларның ведомство буйсынуындагы оешмалары тарафыннан мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча чараларны тормышка ашыру максатларында билгеләнә.

4. Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры яки вазыйфаи бурычларына мәгълүмат иминлеген тәэмин итү буенча, шул исәптән компьютер һөҗүмнәрен ачыклау, кисәтү һәм алар салган зыяннарны бетерү һәм компьютер инцидентларына карата чара күрү вәкаләтләре керә торган Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары:

Техник һәм экспорт контролендә тоту федераль хезмәтенең Идел буе федераль округы буенча идарәсеннән (алга таба – Техник һәм экспорт контролендә тоту

федераль хезмәте), шулай ук Россия Федерациясенең мәгълүмат ресурсларына компьютер һөҗүмнәре ясалуны ачыклау, кисәтү һәм алар салган зыяннарны бетерү буенча дәүләт системасының башка үзәкләреннән максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычының тиешле дәрәҗәсе билгеләнү турында мәгълүмат ала;

бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат алынган көннән бер календарь көн эчендә максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычының тиешле дәрәҗәсе билгеләнү турында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесенә һәм Татарстан Республикасының киберкуркынычсызлыкны тәэмин итү штабы җитәкчесенә хәбәр итә.

5. Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору кысаларында Татарстан Республикасының киберкуркынычсызлыкны тәэмин итү штабы җитәкчесе максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычының тиешле дәрәҗәсе билгеләнү турында мәгълүмат алынган көннән ике календарь көн эчендә:

максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычының тиешле дәрәҗәсе билгеләнү турында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына мәгълүмат бирүне оештыра;

Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору һәм аларның сакланышын арттыру буенча чаралар исемлеген Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына җибәрүне оештыра;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору һәм аларның сакланышын арттыру буенча чаралар күрүне оештыра.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычының тиешле дәрәҗәсе билгеләнү турында мәгълүмат алынганда әлеге мәгълүмат алынган көннән бер календарь көн эчендә:

Техник һәм экспорт контролендә тоту федераль хезмәте белән килештерелгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы җитәкчесе тарафыннан расланган максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычы дәрәҗәләре билгеләнгәндә гамәлгә ашырыла торган чаралар планнарын үти башлый;

ведомство буйсынуындагы оешмаларга максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычының тиешле дәрәҗәсе билгеләнү турында хәбәр итә һәм аларга мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору һәм аларның сакланышын арттыру буенча чаралар исемлеген җибәрә.

7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычының тиешле дәрәҗәсе билгеләнү турында мәгълүмат алынганда әлеге мәгълүмат алынган көннән бер календарь көн эчендә түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору һәм аларның сакланышын арттыру буенча чаралар исемлеген үти башларга;

ведомство буйсынуындагы оешмаларга максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычының тиешле дәрәҗәсе билгеләнү турында хәбәр итәргә һәм аларга мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору һәм аларның сакланышын арттыру буенча чаралар исемлеген җибәрергә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору һәм аларның сакланышын арттыру буенча чараларны тормышка ашыру эшләрен оештыру өчен җаваплылык әлеге органнар җитәкчеләренең мәгълүматны саклау чараларын тәэмин итүгә җавап бирүче урынбасарларына йөкләнә.

9. Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору кысаларында Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычы дәрәҗәләре билгеләнгәндә гамәлгә ашырыла торган чаралар планнарын эшләү, аларны Техник һәм экспорт контролендә тоту федераль хезмәте белән килештерү һәм раслау чараларын оештыра;

максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуны кисәтү буенча карарлар эшли һәм аларны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалу куркынычының тиешле дәрәҗәсе билгеләнгәндә мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору һәм аларның сакланышын арттыру буенча чаралар үтәлешен контрольдә тотуны планлаштыра һәм оештыра;

Татарстан Республикасының мәгълүмат инфраструктурасы объектларына максатчан компьютер һөҗүмнәре ясалуга каршы тору һәм аларның сакланышын арттыру буенча чаралар исемлеген формалаштыру өчен тәкъдимнәр эшли.

______________________